Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 29 июле 60№

Әлки муниципаль районы Советының 2017 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында»гы 90 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль-хосусый партнерлык кысаларында җирле үзидарә органнарының, юридик затларның үзара мөнәсәбәтләрен җайга салу максатларында, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2005 елның 21 июлендәге «Концессия килешүләре турында» 115-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 224-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 29 декабрендәге « Алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 464-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль район Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәгә (2018.17.12, 206№, 2021.30.04, 51№ редак.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 бүлекнең 11 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"11) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийлар нигезендә билгеләнгән җитештерү, беренчел һәм (яисә) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртү, авыл хуҗалыгы продукциясен саклау объектлары;".

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин